# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Петровский торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**27октябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Петровский торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Петровский торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтергә:

- юллар буйлап үләннәр чаптыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Алга авылындагы янгын скважинасын бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Гамәлдәге законнар нигезендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында әлеге карарны игълан итәргә, шул исәптән мәгълүмат стендларында һәм Үзәк авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, Үзәк авыл җирлеге башлыгы
В.Н. Котников

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Петровский торак пунктының гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**27 октябрь 2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,хисап комиссиясенең 2022 елның 27 октябрендә Петровский авылында үткән гражданнар җыены буенча түбәндәге сорау хакында беркетмә төзелде: «Сез Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Петровский авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтүгә ризамы:
- юллар буйлап үләннәр чаптыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- - Алга авылындагы янгын скважинасын бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:
Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 12 кеше кертелгән;
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 12 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:
халык җыенында катнашучы 12 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Петровский торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип санарга: «Сез Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Петровский авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар

һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтүгә ризамы:
- юллар буйлап үләннәр чаптыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- - Алга авылындагы янгын скважинасын бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Гамәлдәге законнар нигезендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында әлеге карарны игълан итәргә, шул исәптән мәгълүмат стендларында һәм Үзәк авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, Үзәк авыл җирлеге
башлыгы: В.Н.Котников